КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 август

г.Казань

№ 755

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы» сүзләрен «2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Киләсе елга бер экспертиза объектына карата хезмәт шартларын махсус бәяләү сыйфатына экспертиза үткәргән өчен түләү күләме ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан агымдагы елның 20 декабренә кадәр раслана һәм ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин